# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

**№ 5**

**май**

1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
1999

# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 5*
*май*
*1999*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
1999

Лицензия № 174 1996 елның 03.10 бирелде
Җитештерүгә тапшырылды
Формат А5. Оригинал-макеттан басылды
Тиражы 1050 нөсхә. Заказы
Бәясе килешү буенча.
"АБАК" нәшрияты.
420045 Казан, Н. Ершов ур., $31^{б}$.
Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять АБАК-хезмәт күрсәтү үзәгендә басылды
Лицензия № 0080 1997 елның 03.12 бирелде
420107 Казан, Һади Такташ ур., 105

*ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696*
**Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы
© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 1999

## Эчтәлек

512.“Этил спирты, алкоголь һәм алкогольле продукция җитештерү һәм аларның әйләнеше өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” *Татарстан Республикасы Законы* ........ 8

513.Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 маендагы утырышы көн тәртибе турында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 18

514.Татарстан Республикасының аерым район, шәһәр судлары судьяларын сайлау һәм Татарстан Республикасының Мамадыш район суды рәисен раслау турында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 19

515.Татарстан Республикасы Мөслим районының Симәк җирле үзидарәсе территориясендә яңа барлыкка килгән Кырын Тау торак пунктын теркәү һәм аңа исем бирү турында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 20

516.“Татарстан Республикасының Арча районы Яңа Кырлай җирле үзидарәсенең Алмалы һәм Яңа Кишет җирле үзидарәсенең Яңа Мәңгәр авылларын исәпкә алу белешмәләреннән төшереп калдыру турында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 21

517.“Вөждан иреге һәм дини берләшмәләр турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында ........ 21

518.“Татарстан Республикасы гражданнарының хокук тәртибен тәэмин итүдә катнашуы турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 22

519.Татарстан Республикасы Прокуратурасының Татарстан Республикасы Конституциясен һәм Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы халык депутатларының кагылгысызлыгын тәэмин итү өлешендә “Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Совет халык депутаты статусы турында” Татарстан Республикасы Законын үтәве хакында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 23

520.Татарстан Республикасында балаларны гепатитка каршы вакциналаштыру турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматы хакында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 24

521.100 млн. АКШ доллары күләмендә “ING Barings” банкыннан алган кредит акчаларыннан файдалану турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты мәгълүматы хакында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 25

522.“Татарстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләренә хезмәт хакы буенча бурычдагы түләүдәге хәл турында” Татарстан Республикасы халык депутаты Ю.П.Прохоров таләбе хакында”*Татарстан*

*Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 25
523.“Чаллы шәһәрендә шәһәр автобуслары җитештерү программасын гамәлгә ашыру чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1996 елның 29 декабрендәге 1088 нче карарын үтәү хакында” Татарстан Республикасы халык депутаты Ф.С.Шәйдуллин таләбе турында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 26
524.”Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе көн тәртибе турында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 26
525.Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кайбер даими комиссияләре составындагы үзгәрешләр турында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 30
526.”Татарстан Республикасы халык депутаты Ә.С.Гобәйдуллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы итеп сайлау турында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* 34
527.”Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте структурасына үзгәрешләр кертү турында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 34
528.”Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынына М.Г.Әхмәтов кандидатурасын килештерү турында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ................ 35
529.”Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад һәм сәнәгать министры урынына С.А.Когогин кандидатурасын килештерү турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 36
530.”Татарстан Республикасының Дәүләт мөлкәтенә идарә итү буенча дәүләт комитеты рәисе урынына В.П.Васильев кандидатурасын килештерү турында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 36
531.”Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Рәисе урынбасарын һәм Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясын сайлау турында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 37
532.Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының судьялары һәм аппаратының хезмәткәрләре гомуми санын раслау турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .................... 38
533.”Татарстан Республикасы халык депутаты М.Ш.Хөсәеновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими нигездә эшләү өчен сайлау турында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* 38
534.“Татарстан Республикасы сайлау системасын камилләштерү белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәреш-

ләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 39
535."Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* . 40
536."Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 41
537."Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 42
538."Уен бизнесына салым турында" 1998 елның 31 июлендәге 142-ФЗ номерлы Федераль законны Татарстан Республикасы территориясендә куллану хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 42
539."Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 43
540."Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алдан билгеләнгән керемгә бердәй салым турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 44
541."Сатудан салым турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 45
542."1999 елга Татарстан Республикасы бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 45
543."Латин графикасына нигезләнгән татар алфавитын торгызу турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* . 46
544."Мактаулы ана" ("Материнская слава") Татарстан Республикасы медален гамәлгә кую турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында"*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 47
545."Гадәттән тыш хәлнең хокукый режимы турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында "*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................ 48

546.“Татарстан Республикасында дәүләт милке һәм җирле үзидарә милке турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* . 48

547.“Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проектын эшләүне дәвам итү хакында”*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......................................... 49

548.”Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре комиссиясе хисабы турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .................................................. 50

## II

549.”Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ..... 51

550.”Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына кертелүче мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары хакында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ....... 52

551.”Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы язгы сессиясенең чираттагы утырышын чакыру турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* .................. 54

552.”1999 елның 20 маенда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында” *Татарстан Республика-сы Дәүләт Советы Президиумы карары* .......................................... 54

553.”1999 елның 20 маенда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары хакында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* .......................................... 55

554.”1999-2001 елларга Татарстан Республикасында наркотикларга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору программасы проекты турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* .................................................................. 56

555.“Татарстан Республикасында ветеринария эше турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законы проекты турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* .......................................... 57

556.”1999 елның 28 апрелендәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында әйтелгән Татарстан Республикасы халык депутатлары тәкъдимнәре турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* .......................................... 58

557.”Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ..... 58

558.”Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар

сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ..... 60
559. "Татарстан Республикасында гаилә сәясәте концепциясе турында" дигән темага парламент тыңлауларын үткәрү хакында" *Татар-стан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* .................... 61

## III

560. "Салым түләүләрен вакытында күчермәгән өчен банк учреждениеләренең җаваплылыгын көчәйтү чаралары турында" Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ... 62
561. Татарстан Республикасында хосусыйлаштыру процессында төзелгән акционерлык җәмгыятьләре акцияләре әйләнешен вакытлыча чикләүне бетерү турында" *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........................................................................................ 63

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 512. “Этил спирты, алкоголь һәм алкогольле продукция җитештерү һәм аларның әйләнеше өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

“Этил спирты, алкоголь һәм алкогольле продукция җитештерү һәм аларның әйләнеше өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында” Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997 ел, № 1-2) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә, аны түбәндәгечә бәян итәргә:

**“Этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерү һәм (яисә) аларның әйләнеше өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында**

**Татарстан Республикасы Законы**

Бу Закон этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерү һәм (яисә) аларның әйләнеше өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылыкны билгели, дәүләт контролен көчәйтүгә, ясалма (ялган) продукция җитештерү һәм сатуны булдырмауга, гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклауны , дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

1 статья. **Төп төшенчәләр һәм билгеләмәләр**

Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция әйләнеше – этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне читкә чыгару, читтән кайтару, китереп тору, сатып алу, саклау,

ташу, күпләп һәм ваклап сату;

этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне күпләп сату – юридик зат, индивидуаль эшкуар җитештерә яисә сатып ала торган (кабул итеп алына, сатып алына торган) продукцияне башка юридик затка, шәхси эшмәкәргә яңадан сату (китереп тору, тапшыру) максатында бирү (сату, китереп тору, шул исәптән уртак эшчәнлек, комиссияләү, йөкләүләр турында шартнамә нигезендә һ.б.) буенча эшкуарлык эшчәнлеге.

2 статья. **Әлеге Законның гамәлдә булу чикләре**

Бу Законда каралган хокук бозулар өчен законнар нигезендә җинаять җаваплылыгы билгеләнерлек булмаса, административ җаваплылык чаралары карала.

Әлеге Закон гамәлләре граждан (физик зат) этикеткалардан, товар билгеләреннән файдаланмыйча, тамгаламыйча җитештергән, сату өчен булмаган алкоголь продукциясенә һәм спиртлы продукциягә кагылмый.

3 статья. **Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне тиешле лицензиясез, шулай ук лицензия таләпләрен һәм шартларын бозып җитештерү һәм (яисә) әйләнештә йөртү, саклау**

Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне тиешле лицензиясез җитештергән һәм (яисә) әйләнештә йөрткән өчен –

гражданнарга хезмәт өчен түләүнең уннан алып йөз минималь күләменә кадәр, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, индивидуаль эшкуарларга, этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең илледән алып ике йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне лицензия таләпләрен һәм шартларын бозып җитештергән һәм (яисә) әйләнештә йөрткән өчен –

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, индивидуаль эшкуарларга хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

Предприятиеләрдә (оешмаларда) башка юридик затның, шәхси эшмәкәрнең яисә гражданның этил спиртын, алкоголь

һәм спиртлы продукциясен әлеге эшчәнлек төренә лицензиясез саклаган өчен –

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, индивидуаль эшкуарларга, этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең йөздән алып ике йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

4 статья. **Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты каршындагы Татарстан Республикасының Алкоголь продукциясенә дәүләт монополиясен тәэмин итү дәүләт инспекциясенең квоталарыннан һәм (яисә) махсус рөхсәтеннән башка, шулай ук квота булып, аның күләмнәрен арттырып җитештерү һәм (яисә) әйләнештә йөртү**

Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты каршындагы Татарстан Республикасының Алкоголь продукциясенә дәүләт монополиясен тәэмин итү дәүләт инспекциясенең квоталарыннан һәм (яисә) махсус рөхсәтеннән башка, шулай ук квота булып, аның күләмнәрен арттырып җитештергән һәм (яисә) әйләнештә йөрткән өчен –

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, индивидуаль эшкуарларга, этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең илледән алып ике йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

5 статья. **Сату тыелган этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм (яисә) аларның әйләнеше**

Сату тыелган этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне җитештергән һәм (яисә) аларны әйләнешкә керткән өчен –

гражданнарга хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз

минималь күләменә кадәр һәм предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, индивидуаль эшкуарларга, этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**6 статья. Тиешле үрнәктәге билгеләр белән тамгаланмаган алкоголь продукциясе әйләнеше**

Тиешле үрнәктәге билгеләр белән тамгаланмаган алкоголь продукциясе әйләнеше өчен –

гражданнарга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр һәм предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, индивидуаль эшкуарларга, алкоголь продукциясен конфискацияләп яисә аннан тыш, хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**7 статья. Алкоголь һәм спиртлы продукцияне билгеләнгән сәүдә нормаларын һәм кагыйдәләрен бозып сату**

Алкоголь һәм спиртлы продукцияне билгеләнгән сәүдә нормаларын һәм кагыйдәләрен бозып саткан өчен –

гражданнарга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр һәм предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, индивидуаль эшкуарларга хезмәт өчен түләүнең уннан алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**8 статья. Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне җитештерүгә һәм (яисә) әйләнештә йөртүгә тиешле лицензиясе булмаган җитештерүчедән яки күпләп сатучыдан алынган продукция әйләнеше**

Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне җитештерүгә һәм (яисә) әйләнештә йөртүгә тиешле лицензиясе булмаган җитештерүчедән яки күпләп сатучыдан алынган продукция әйләнеше өчен –

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, индивидуаль эшкуарларга, этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне конфискацияләп,

хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

9 статья. **Сыйфат һәм куркынычсызлык, төрү һәм тамгалау буенча норматив-техник документлар таләпләренә туры килми торган, республика тәңгәллек сертификаты яки аның билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсе булмаган, сертификат билгеләре белән тамгаланмаган (Татарстан Республикасына читтән кертелә торган алкоголь продукциясе өчен) этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм (яисә) әйләнештә йөртү**

Сыйфат һәм куркынычсызлык, төрү һәм тамгалау буенча норматив-техник документлар таләпләренә туры килми торган, республика тәңгәллек сертификаты яки аның билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсе булмаган, сертификат билгеләре белән тамгаланмаган (Татарстан Республикасына читтән кертелә торган алкоголь продукциясе өчен) этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне җитештергән һәм (яисә) әйләнештә йөрткән өчен –

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, индивидуаль эшкуарларга, этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне конфискацияләп яисә аннан тыш, хезмәт өчен түләүнең уннан алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

10 статья. **Билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве узмаган этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм (яисә) әйләнештә йөртү**

Тиешле тәртиптә дәүләт теркәве узмаган этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне җитештергән һәм (яисә) әйләнештә йөрткән өчен –

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, индивидуаль эшкуарларга хезмәт өчен түләүнең илледән алып ике йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

11 статья. **Ясалма (ялган) алкоголь продукциясен җитештерү һәм (яисә) әйләнештә йөртү, этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне ялган документлар белән әйләнештә йөртү, алкоголь продукциясен ялган махсус һәм ялган сертификация билгеләре белән әйләнештә йөртү**

Ясалма (ялган) алкоголь продукциясен җитештергән һәм (яисә) әйләнештә йөрткән өчен, этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне ялган документлар белән әйләнештә йөрткән, алкоголь продукциясен ялган махсус һәм ялган сертификация билгеләре белән әйләнештә йөрткән өчен –

гражданнарга, этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең уннан алып йөз минималь күләменә кадәр, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, индивидуаль эшкуарларга, этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең илледән алып ике йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

12 статья. **Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукция не тиешенчә рәсмиләштерелмәгән исәпкә алу, финанс һәм товар йөртү документларыннан башка әйләнештә йөртү**

Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне тиешенчә рәсмиләштерелмәгән исәпкә алу, финанс һәм товар турындагы документлардан башка әйләнештә йөрткән өчен –

предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, индивидуаль эшкуарларга, этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне конфискацияләп яисә аннан тыш, хезмәт өчен түләүнең уннан алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

13 статья. **Билгеләнгән тәртиптә рәсми исәпкә алынмаган этил спиртын, спиртлы һәм алкоголь продукциясен саклау һәм (яисә) сату**

Этил спиртын, спиртлы һәм алкоголь продукциясен җитештерүче һәм (яисә) сатучы предприятиеләрдә билгеләнгән тәртиптә рәсми исәпкә алынмаган этил спиртын, спиртлы һәм алкоголь продукциясен саклаган һәм (яисә) саткан өчен –

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, индивидуаль эшкуарларга, этил спиртын, спиртлы һәм алкоголь продукциясен конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең уннан алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

14 статья. **Бәяләрнең дәүләт дисциплинасын бозу**

Этил спиртына һәм алкоголь продукциясенә билгеләнгән күпләп сатып җибәрү (ваклап сату) бәяләрен һәм сәүдә өстәмәләрен бозган өчен –

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, индивидуаль эшкуарларга хезмәт өчен түләүнең уннан алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

15 статья. **Спирт үлчәү, исәпләү приборларына, технология җиһазларына, этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерелә һәм (яисә) саклана торган биналарга вәкаләтле урындагы зат салган мөһерне (пломбаны) бозу яисә алып ташлау**

Спирт үлчәү, исәпләү приборларына, технология җиһазларына, этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерелә һәм (яисә) саклана торган биналарга вәкаләтле урындагы зат салган мөһерне (пломбаны) бозган яисә алып ташлаган өчен, –

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, индивидуаль эшкуарларга хезмәт өчен түләүнең илледән алып ике йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

16 статья. **Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты каршындагы Татарстан Республикасының Алкоголь продукциясенә дәүләт монополиясен тәэмин итү дәүләт инспекциясенең күрсәтмәләрен үтәмәгән юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның җаваплылыгы**

Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты каршындагы Татарстан Республикасының Алкоголь продукциясенә дәүләт монополиясен тәэмин итү дәүләт инспекциясенең:

этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерү һәм (яисә) аларның әйләнеше нормаларын, кагыйдәләрен бозуны бетерү турындагы;

этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм (яисә) аларның әйләнешен туктатып тору турындагы;

этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерү һәм (яисә) аларның әйләнеше өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле документлар һәм мәгълүматлар бирү турындагы күрсәтмәләрне бозган өчен –

хезмәт өчен түләүнең биш мең тапкыр минималь күләменә кадәр штраф салына.

17 статья. **Этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерү һәм (яисә) аларның әйләнеше өлкәсендә административ хокук бозулар турындагы эшләрне карауга вәкаләтле органнар (урындагы затлар)**

Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләр район (шәһәр) судлары тарафыннан карала. Бу Законның 3 статья (2 өлеше), 7,10,14,15, һәм 16 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты каршындагы Татарстан Республикасының Алкоголь продукциясенә дәүләт монополиясен тәэмин итү дәүләт инспекциясе һәм (16 статьяда каралганнарыннан гайреләрен) кулланучылар хокукларын як-

лау буенча территория (район, шәһәр) комитетлары каршындагы вәкаләтле территория органнары карый.

Административ хокук бозулар турындагы эшләрне Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты каршындагы Татарстан Республикасының Алкоголь продукциясенә дәүләт монополиясен тәэмин итү дәүләт инспекциясе исеменнән Дәүләт инспекциясе башлыгы яисә аның урынбасарлары, аның вәкаләтле территория органы исеменнән әлеге органның җитәкчесе яисә аның урынбасарлары карый.

18 статья. **Административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр**

Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитетының, аның территория (район, шәһәр) комитетларының, Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты каршындагы Татарстан Республикасының Алкоголь продукциясенә дәүләт монополиясен тәэмин итү дәүләт инспекциясенең, аның кулланучылар хокукларын яклау буенча территория (район, шәһәр) комитетлары каршындагы территориаль органнарының, эчке эшләр органнарының, Татарстан Республикасы буенча Дәүләт салым инспекциясенең, Россия Федерациясе салым полициясенең Татарстан Республикасы буенча федераль хезмәт идарәсенең шуңа вәкаләтле урындагы затлары тарафыннан төзелә.

19 статья. **Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау**

Әлеге Законда күрсәтелгән хокук бозулар турындагы эшләр административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта карала.

20 статья. **Штрафлар суммасын бүлү**

Әлеге Законның 3-15 статьяларында каралган штрафлар суммасы түбәндәгеләргә юнәлтелә: 25 проценты – хокук бозулар булган шәһәр һәм районнар бюджетларына; 75 проценты – хокук бозуларны ачыклаган орган счетына.

Бу Законның 16 статьясында каралган штрафлар суммасы Татарстан Республикасының республика бюджетына җибәрелә.

21 статья. **Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне тартып алу**

Әлеге Законның 3-14 статьяларында күрсәтелгән хокук бозулар белән җитештерелә һәм (яисә) әйләнештә йөри торган этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция әлеге Законның 18 статьясында санап кителгән органнарның урындагы вәкаләтле затлары тарафыннан тартып алынырга мөмкин.

Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне тартып алганда беркетмә тутырыла яки административ хокук бозу турындагы беркетмәгә тиешенчә язып куела.

Тартып алынган продукциягә норматив-техник документларда билгеләнгән куркынычсызлык таләпләренә туры килү-килмәү буенча мәҗбүри экспертиза үткәрелергә тиеш һәм ул, эш каралганчыга кадәр, әлеге Законның 18 статьясында санап кителгән органнарның вәкаләтле затлары билгели торган урыннарда сакланырга тиеш.

Эшне караганнан соң, карау нәтиҗәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә тартып алынган продукция конфискацияләнә йә хуҗасына кире кайтарып бирелә.

Әлеге Закон нигезендә административ җәза бирелгәндә тартып алынган продукцияне саклауга, ташуга, аңа мәҗбүри экспертиза үткәрүгә һәм аны юк итүгә бәйле чыгымнарны продукция хуҗасы түли.

Кызыксынучы затлар этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне тартып алуга карата билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерергә мөмкин.

22 статья. **Конфискацияләнгән продукциядән файдалануны дәвам итү**

Дәүләт стандартлары таләпләренә җавап бирми торган, кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы конфискацияләнгән продукция билгеләнгән тәртиптә юк ителергә тиеш.

Дәүләт стандартлары таләпләренә туры килми торган, ләкин кешеләр сәламәтлегенә куркыныч тудырмаучы конфискацияләнгән продукция промышленностьтә кабат эшкәртелергә тиеш.

Дәүләт стандартларының барлык таләпләренә дә туры килә торган конфискацияләнгән продукция билгеләнгән тәртиптә сатыла.

Конфискацияләнгән продукцияне сатудан һәм эшкәртүдән кергән акча, аны саклауга, транспортлауга, сатуга, мәҗбүри экспертиза уткәругә киткән чыгымнарны тотып калганнан соң, Татарстан Республикасының республика бюджетына җибәрелә.

23 статья. Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә."

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 28 апреле
№ 2102

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 513. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 маендагы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 маендагы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. "Татарстан Республикасының аерым район, шәһәр судлары судьяларын сайлау турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

2. "Продукцияне бүлешү турында килешүләр хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында.

3. "Продукция бүлешү турындагы килешүләр шартларында файдалану хокукы бирелергә мөмкин булган җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлеге хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында.

4. "Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

5. "Вөждан иреге һәм дини берләшмәләр турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

6. "Алабуга" ирекле икътисадый зонасы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында"' Татарстан Республикасы законы проекты турында.

7. "Татарстан Республикасы гражданнарының хокук тәртибен тәэмин итүдә катнашуы турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

8. “Татарстан Республикасының Арча районы Яңа Кырлай җирле үзидарәсенең Алмалы һәм Яңа Кишет җирле үзидарәсенең Яңа Мәңгәр авылларын исәп белешмәләреннән төшереп калдыру турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

9. 100 млн. АКШ доллары суммасында Голландия банкы биргән кредиттан файдалану турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте мәгълүматы.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 мае
№ 2133

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## Д ӘЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 514. Татарстан Республикасының аерым район, шәһәр судлары судьяларын сайлау һәм Татарстан Республикасының Мамадыш район суды рәисен раслау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Судьялар итеп сайларга:
Казан шәһәренең Авиатөзелеш район судына:
Әлфия Шәйхетдин кызы Нуретдинованы,
Айдар Вәгыйз улы Сабирҗановны;
Казан шәһәренең Идел буе район судына:
Галина Васильевна Рупованы,
Наталия Васильевна Цветкованы,
Алексей Николаевич Чернышевны;
Казан шәһәренең Совет район судына
Гөлшат Миңнерәкыйп кызы Хәлитованы;
Татарстан Республикасының Әгерҗе район судына
Әлфия Фәйзи кызы Галәвиеваны;
Татарстан Республикасының Баулы шәһәр судына
Мөнәздәһә Мөслим кызы Гыйльметдинованы;

Татарстан Республикасының Буа район судына Рафаэль Раҗетдин улы Шамионовны;

Татарстан Республикасының Бөгелмә шәһәр судына Фәһим Мәхмүт улы Мифтаховны;

Татарстан Республикасының Биектау район судына Гөлнур Әмир кызы Сәгъдиеваны;

Татарстан Республикасының Мамадыш район судына: Зиннур Миңнәхмәт улы Муллахмәтовны һәм аны,

Татарстан Республикасының Чистай шәһәр суды судьясы вазыйфаларыннан азат итеп, әлеге суд рәисе итеп расларга,

Хәйдар Баян улы Сәлаховны.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 мае
№ 2134

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 515. Татарстан Республикасы Мөслим районының Симәк җирле үзидарәсе территориясендә яңа барлыкка килгән Кырын Тау торак пунктын теркәү һәм аңа исем бирү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Мөслим районының Симәк җирле үзидарә территориясендә яңа барлыкка килгән торак пунктын теркәргә һәм исәпкә алу белешмәләренә кертергә, аңа Кырын Тау авылы дигән исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 мае
№ 2137

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 516. "Татарстан Республикасының Арча районы Яңа Кырлай җирле үзидарәсенең Алмалы һәм Яңа Кишет җирле үзидарәсенең Яңа Мәңгәр авылларын исәпкә алу белешмәләреннән төшереп калдыру турында"

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Халкы башка торак пунктларга күчеп китүгә бәйле рәвештә "Татарстан Республикасының Арча районы Яңа Кырлай җирле үзидарәсенең Алмалы һәм Яңа Кишет җирле үзидарәсенең Яңа Мәңгәр авылларын исәпкә алу белешмәләреннән төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 ел 20 мае
№ 2138

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 517. "Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында" Татарстан Республика законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. "Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында" Татарстан Республикасы законы проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе кат-

нашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дәрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 мае
№ 2139

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 518. "Татарстан Республикасы гражданнарының хокук тәртибен тәэмин итүдә катнашуы турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Татарстан Республикасы гражданнарының хокук тәртибен тәэмин итүдә катнашуы турында" Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсәләләре комиссиясенә 1999 елның 20 июнендә кертелә, дип билгеләргә.

3. Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсәләләре комиссиясе 1999 елның 20 июленә кадәр әлеге закон проектын, кергән искәрмәләрне һәм төзәтмәләрне исәпкә алып, эшләп бетерергә һәм икенче укылышта Дәүләт Советы каравына кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 мае
№ 2140

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 519. Татарстан Республикасы Прокуратурасының Татарстан Республикасы Конституциясен һәм Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы халык депутатларының кагылгысызлыгын тәэмин итү өлешендә "Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Совет халык депутаты статусы турында" Татарстан Республикасы Законын үтәве хакында

Әлеге мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасары В.Г.Метелин мәгълүматын тыңлап һәм тикшереп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Прокурорына:

Татарстан Республикасы Конституциясенең 153 статьясын үтәүдә үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы законнарын катгый үтәү нигезендә башкарырга;

Татарстан Республикасы Конституциясенең 86 статьясын һәм "Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты статусы турында" Татарстан Республикасы Законының 25 статьясын бозып кузгатылган җинаять эшләрен яңадан карау чараларын күрергә, бу турыда әлеге карар кабул ителгән көннән өч ай вакыт эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына хәбәр итәргә.

2. Татарстан Республикасы Конституциясенең 156 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә, Татарстан Республикасы Прокуратурасы катнашында, 1 июльгә кадәр вакыт эчендә "Татарстан Республикасы Прокуратурасы турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә.

3. Әлеге карарның 1 пунктын үтәүне тикшереп торуны

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 мае
№ 2141

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 520. Татарстан Республикасында балаларны гепатитка каршы вакциналаштыру турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасында балаларны гепатитка каршы вакциналаштыру турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына 1999 елның 1 июленә кадәр 2000-2005 елларга "Йогышлы авыруларны вакциналап кисәтү" Республика программасын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 мае
№ 2142

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 521. 100 млн. АКШ доллары күләмендә "ING Barings" банкыннан алган кредит акчаларыннан файдалану турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты мәгълүматы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

100 млн. АКШ доллары күләмендә "ING Barings" банкыннан алган кредит акчаларыннан файдалану турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты мәгълүматын игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 мае
№ 2143

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 522. "Татарстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләренә хезмәт хакы буенча бурычдаогы түләүдәге хәл турында" Татарстан Республикасы халык депутаты Ю.П.Прохоров таләбе хакында

Татарстан Республикасы халык депутаты Ю.П.Прохоров таләбе буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

"Татарстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләренә хезмәт хакы буенча бурычларны түләүдәге хәл турында" Татарстан Республикасы халык депутаты Ю.П.Прохоров таләбенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 мае
№ 2144

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 523. “Чаллы шәһәрендә шәһәр автобуслары җитештерү программасын гамәлгә ашыру чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1996 елның 29 декабрендәге 1088 нче карарын үтәү хакында” Татарстан Республикасы халык депутаты Ф.С.Шәйдуллин таләбе турында

Татарстан Республикасы халык депутаты Ф.С.Шәйдуллин таләбе буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

“Чаллы шәһәрендә шәһәр автобуслары җитештерү программасын гамәлгә ашыру чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1996 елның 29 декабрендәге 1088 нче карарын үтәү хакында” Татарстан Республикасы халык депутаты Ф.С.Шәйдуллин таләбенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 мае
№ 2145

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 524. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы унтугызынчы пленар сессиясенең түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Кайбер сайлау округлары буенча Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлау нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе мәгълүматы.

2."Татарстан Республикасы халык депутаты Ә.С.Гобәйдуллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы итеп сайлау турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кайбер даими комиссияләре составындагы үзгәрешләр турында.

4. "Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте структурасына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

5."Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынына М.Г.Әхмәтов кандидатурасын килештерү турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

6. "Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад һәм сәнәгать министры урынына С.А.Когогин кандидатурасын килештерү турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

7. "Татарстан Республикасының Дәүләт мөлкәте белән идарә итү дәүләт комитеты рәисе урынына В.П.Васильев кандидатурасын килештерү турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

8. "Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясын сайлау һәм Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Рәисе урынбасарын раслау турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

9. "Татарстан Республикасының сайлау системасын камилләштерүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

10. "Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында.

11."Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проекты

турында.

12.“Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

13. “Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 111 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

14. “Иминлек турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

15. “Уен бизнесына салым турында” 1998 елның 31 июлендәге 142-ФЗ номерлы Федераль законны Татарстан Республикасы территориясендә куллану хакында” Татарстан Республикасы законы проекты турында.

16. “Сатудан салым турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

17.“1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында” Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законы проекты турында.

18. “Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алдан билгеләнгән керемгә бердәм салым турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

19.“Сбс-АГРО” АКБ өчен Россия Федерациясе Үзәк банкына җаваплылык йөкләмәсен тапшыру турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары хакында.

20. “Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының җаваплылык йөкләмәсе турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

21.“Альфа-Банк” ачык акционер җәмгыяте өчен Россия Федерациясе Үзәк банкына җаваплылык йөкләмәсен тапшыру турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

22.“Татарстан Республикасының бюджеттан тыш дәүләт фондлары турында” Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

23. “Җир өчен түләү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законы проекты турында.

24. 1999-2000 елларга “Татарстан яшьләре” дәүләт программасы проекты турында.

25. “1999-2001 елларга Татарстан Республикасында наркотиклардан усал нияттә файдалануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору комплекслы чаралары” республика максатчан программасы проекты турында.

26. “Латин графикасына нигезләнгән татар алфавитын торгызу турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

27. “Мактаулы ана” (“Материнская слава”) Татарстан Республикасы медален гамәлгә кую турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

28. “Гадәттән тыш хәлнең хокукый режимы турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

29. “Татарстан Республикасында дәүләт милке һәм җирле үзидарә милке турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

30.“Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

31. “Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының штат санын раслау турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

32. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре даими комиссиясе эше турында хисап.

33.“Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

34.Татар телендә телевидение, радио тапшыруларын саклап калу һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан күрелүче чаралар турында.

35.“Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында” Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклап калу, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын үтәүнең барышы хакында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1997 елның 22 маендагы 1174 нче карарын 2000 елга кадәр Татар милли университетын ачу өлешендә үтәүнең барышы турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте мәгълүматы.

36.“Татарстан Республикасы халык депутаты М.Ш.Хө-

сәеновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими нигездә эшләү өчен сайлау турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 26 мае
№ 2155

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 525. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кайбер даими комиссияләре составындагы үзгәрешләр турында

Татарстан Республикасы халык депутатлары Р.М.Закиров, Э.Н.Фәттахов, И.Н.Сабиров, Н.Н.Хәбипов, В.Г.Осянин, Р.Г.Шәяхмәтов, Җ.А.Гафуров, Ф.И.Һидиятуллин, Л.Г.Гайсин, Н.М.Владимиров, В.М.Козлов, Ш.Г.Насыйбуллин, Р.Г.Хәйруллин, Р.С.Хөсәенов, С.М.Кәлимуллин гаризаларын карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. 27 нче Арча административ-территория сайлау округыннан Татарстан Республикасы халык депутаты Сабиров Илһам Наил улын, 34 нче Биек Тау административ-территория сайлау округыннан Шәяхмәтов Рәшит Габделхәй улын, 52 нче Балык Бистәсе административ-территория сайлау округыннан Хәйруллин Равил Гарифулла улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре даими комиссиясе әгъзасы итеп сайларга.

2. "Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре даими комиссиясе составы турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1995 елның 26 апрелендәге аннан соңгы үзгәрешләр белән карарына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

1 абзацта "20" саны урынына "19" санын язарга;

2 абзацка түбәндәгеләрне өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| "Сабиров Илһам Наил улы | - | 27 нче Арча административ-территория сайлау округы |

| | | |
|---|---|---|
| Шәяхмәтов Рәшит Габделхәй улы | - | 34 нче Биек Тау административ-территория сайлау округы |
| Хәйруллин Равил Гарифулла улы | - | 52 нче Балык Бистәсе административ-территория сайлау округы" |

3. 29 нчы Баулы административ-территория сайлау округынан Хәбипов Нурислам Нуриман улын, 45 нче Менделеевски административ-территория сайлау округыннан Гайсин Ленар Гайнулла улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре даими комиссиясе әгъзалары итеп сайларга.

4. "Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре даими комиссиясе составы турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1995 елның 26 апрелендәге аннан соңгы үзгәрешләр белән карарына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

1 абзацта "13" саны урынына "15" санын язарга;

2 абзацта түбәндәгеләрне өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| "Хәбипов Нурислам Нуриман улы | - | 29 нчы Баулы административ-территория сайлау округы |
| Гайсин Ленар Гайнулла улы | - | 45 нче Менделеевски административ-территория сайлау округы" |

5. 22 нче Актаныш административ-территория сайлау округыннан Татарстан Республикасы халык депутаты Фәттахов Энгель Нәвап улын, 44 нче Мамадыш административ-территория сайлау округыннан Һидиятуллин Фарук Ислам улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләре даими комиссиясе әгъзалары итеп сайларга.

6. "Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре даими комиссиясе составы турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1995 елның 26 апрелендәге аннан соңгы үзгәрешләр белән карарына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

2 абзацта түбәндәгеләрне өстәргә:

| | |
|---|---|
